**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ.**

# КАРАР

2019ел, 30.12. № 233

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә турында яңа редакциядә» 2018 елның 24 августындагы 158 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә («Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәнең яңа редакциясендә» Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының 2018 елның 24 августындагы 158 нче номерлы карары белән расланды) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) уналтынчы бүлеккә:

а) 16.1 пунктының 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында оештырылган беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан түләүсез катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек хуҗалары ширкәтләренең съездында (конференциядә) яки гомуми җыелышында катнашу;

б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә бушлай катнашу (сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, башка иҗтимагый оешманың, торак, гараж кооперативларының, күчемсез милек хуҗалары ширкәтләренең съездда (конференциядә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш) эшкә алучы вәкиле рөхсәте белән, ул Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә алынган;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре Советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек тарафыннан оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә кую тәртибен йә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр белән) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;»

б) түбәндәге эчтәлекле 2.1 өлеш өстәргә:

«2.1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;»

2) 32 бүлектәге 32.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32.3. Дисциплинар җәзаларны куллану һәм алу тәртибе, әлеге Нигезләмәдә каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.»

3) 33 бүлекнең 33.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«33.9. Әлеге Нигезләмәнең 17, 18 һәм 32 бүлекләрендә каралган түләтүләр, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә сәләтсез булу чорын, отпускта булуын исәпкә алмыйча, коррупцион хокук бозу турындагы мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча һәм коррупциячел хокук бозу кылган көннән өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән срокларда җинаять эше буенча җитештерү вакыты кертелми.

Әлеге Нигезләмәнең 17, 18 һәм 32 бүлекләрендә каралган түләтүләр, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә сәләтсез булу чорын, отпускта булуын исәпкә алмыйча, коррупцион хокук бозу турындагы мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча һәм коррупциячел хокук бозу кылган көннән өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән срокларда җинаять эше буенча җитештерү вакыты кертелми.»

2.Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга. http://aksubayevo.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Аксубай муниципаль район Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе К. К. Гилманов